УДК 373.32

# ТАТАР БАЛАЛАР БАКЧАЛАРЫНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮ АЛШАРТЛАРЫ ҺӘМ БЕРЕНЧЕ АДЫМНАРЫ (XX НЧЕ ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРЕГЕ)

***А.Ә. Зиннәтуллина***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*jamash.00@mail.ru*

Тәкъдим ителгән мәкаләдә Октябрь революциясенә кадәр Россия территориясендә кайбер эшләп килгән мәктәпкәчә балалар оешмаларына кыскача күзәтү ясала. Революциядән соң яңа тармак буларак мәгариф системасына кертелгән мәктәпкәчә тәрбия эшенең максаты һәм бурычлары, төрләре, татарлар арасында аларны оештуры юллары күрсәтелә. Бу эш белән шөгыльләнгән беренче татар педагогларының исемнәре искә алына, аларның нинди чыганакларга таянып эш иткәннәре ассызыклана.

**Төп төшенчәләр:** балалар бакчалары, ясләләр, мәктәпкәчә балалар оешмалары, мәктәпкәчә тәрбия, хезмәт тәрбиясе, тән тәрбиясе, физик тәрбия

Кешенең киләчәк тормышына төп нигез балалык чорының мәктәпкәчә дәверендә салына башлауга карамастан, Октябрь революциясенә кадәр мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү эшенә дәүләт тарафыннан игътибар бирелми. Бу вакытта Россия территориясендә фәкать шәхси кешеләр яки хәйрия җәмгыятьләре тарафыннан оештырылган балалар оешмалары гына яшәп килә.

Россиядә балалар бакчалары оештыру тәҗрибәсе XIX гасырның икенче яртысыннан тормышка ашырыла башлый. Ул ике юл белән алып барыла. Беренчесе – югары катлау балалары өчен немец педагогы Г. Фребель системасына нигезләнеп оештырылган шәхси балалар бакчалары. Казан шәһәрендә әлеге системага нигезләнгән беренче балалар бакчасы Берлиндагы Фребель курсларын тәмамлап кайткан А.А. Самойлова тарафыннан 1907 елда оештырыла. 1917 елга шәһәрдә өч түләүле Фребель балалар бакчасы эшләп килә [9, с. 307]. Бу, әлбәттә, рус халкының югары катлау балалары өчен ачылган бакчалар була.

Икенчесе, хатын-кыз хезмәтен киң куллана башлау нәтиҗәсендә эшче гаиләләре балалары өчен завод-фабрикалар каршында оештырылган балалар оешмалары. Бу эшкә беренчеләрдән булып фабрикант И.И. Алафузов керешә. 1900 елның 28 августында фабрикант үз предприятиясендәге эшче хатын-кызларның балалары өчен мәктәп бинасында беренче ясле ача. Ан-

да балалар тиешле тәрбия һәм күзәтү астында ике яшькә кадәр тәрбияләнә алганнар [6, с. 195]. Алафузов завод-фабрикаларында татар хатын-кызлары да эшләвен исәпкә алсак, әлеге оешмаларда мөселман балалары да тәрбияләнгән дип санарга җирлек бар.

Шулай ук революциягә кадәр чыккан татар вакытлы матбугаты битләрендә дә балалар бакчалары, җәйге мәйданчыклар оештырылу турында мәгълүматлар очрый. Мәсәлән, 1915 елгы «Тормыш» газетасы язуы буенча, Уфа шәһәрендә 16 майда балалар бакчасы ачу тантанасы булган. Ачылган көнне бакчага 130 бала яздырылган. Монда балаларны яшьләренә карап төркемнәргә бүлгәннәр. Балалар белән иртәнге 9 дан 11 гә кадәр һәм өйләдән соң сәгать дүрттән җидегә кадәр шөгыльләнгәннәр, ягъни сәламәтлек өчен файдалы булганнар төрле уеннар уйнатканнар [1]. Шул ук газета хәбәр итүенчә, май башыннан Петропавловск (Кызылъяр) шәһәрендә дә хәйрия җәмгыяте тарафыннан балалар бакчасы ачыла. Балалар һәр көнне иртәнге сәгать 8 дән кичке 7 гә кадәр төрле хәрәкәтле уеннар уйнап вакыт уздырганнар, атнасына бер мәртәбә табигать кочагына чыгып сәяхәт кылганнар. Газета билгеләвенчә, әлеге бакчага йөрүче балаларның өчтән бер өлешен мөселман балалары тәшкил иткән [2].

Күренгәнчә, революциягә кадәр рус булмаган милләт вәкилләре өчен махсус балалар бакчалары оештырылмаса да, балаларның билгеле бер өлеше мәктәпкәчә тәрбия челтәреннән читтә калмый.

Татар халкы арасында мәгърифәтчелек идеяләре үтеп керә башлау белән, балага кече яшьтән дөрес тәрбия бирүнең, аның сәламәтлеген кайгыртуның әһәмиятен ассызыклаган хезмәтләр дөнья күрә башлый. Татар педагогларыннан беренче булып әлеге мәсьәләгә әһәмият биргән галим булып Каюм Насыйри санала. Аның «Бала тәрбияләүче аналарга теләкләр» китабы бу юнәлештә татар телендә язылган беренче китап булып тора. Педагог үзенең кече яшьтәге балаларны тәрбияләү турындагы фикерләрен фәнни яктан дәлилләп, ата-аналарга тәрбия, бигрәк тә тән тәрбиясе, буенча тәкъдимнәр бирә [11, с. 37].

Татар халкы арасында җәдитчелек хәрәкәте таралу белән, бала тәрбиясенә багышланган хезмәтләр саны тагын да арта. Фәхрелбанат Сөйләмания, Риза Фәхретдин, Мәрьям Акчурина, Галимәтелбанат Биктимерия һ. б. хезмәтләре моның ачык мисалы.

Димәк, инде революциягә кадәр үк хатын-кыз хезмәте киң кулланыла башлау белән, мәктәпкәчә тәрбия оешмаларына ихтыяҗ туа, педагоглар һәм галимнәр тарафыннан мәктәпкәчә тәрбиянең әһәмияте таныла, күпмедер күләмдә теоретик мәгълүмат барлыкка килә, тәҗрибә туплана башлый.

Октябрь революциясеннән соң илдәге кискен борылышлар мәгариф өлкәсенә дә зур йогынты ясый. Бер яктан, белем бирү тулысынча дәүләт карамагына күчерелеп, аның максаты, бурычлары һәм эчтәлеге тамырдан үзгәрсә, икенче яктан, структур яктан үзгәрешләр дә кертелә, мәгариф челтәрендә мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү тармагы барлыкка килә.

Совет дәүләте, мәктәпкәчә тәрбия эшен үз карамагына алып, җәмгыятьтә барлыкка килгән ике төп мәсьәләне тормышка ашыру максатын куя: беренчедән, эшләүче хатын-кызлар иҗтимагый тормышта күбрәк катнаша алсыннар өчен, аларны бала караудан вакытлыча азат итү; икенчедән, балаларга тиешле дәрәҗәдә тәрбия һәм белем бирү, аларны сәламәт яшәү мохитенә күнектерү.

Дәүләт тарафыннан мәктәпкәчә балалар бакчалары оештыру эше 1918 елдан тормышка ашырыла башлый. Казанда шул елның көзенә 9 балалар бакчасы барлыкка килсә, татар балалары өчен бакчалар 1919 елдан эшли башлый. Бу елны яңа ачылган 40 бакчаның 7се татар балалар бакчасы була. Алар Иске Татар, Яңа Татар, Пороховой бистәләрендә оештырыла [9, с. 307]. Шул ук елны балалар бакчасы оештыру эше авылларда да башланып китә. Мәсәлән, Казан артында беренче балалар бакчасы 1919 елда Кече Солабаш авылында ачыла [10, 57 б.].

Мәктәпкәчә тәрбия йортлары оешуның беренче елларында тәрбия буенча бердәм система, расланган бердәм юнәлеш булмый. Күп очракта «мөстәкыйль тәрбия теориясе», Фребель һәм Монтессори системаларының кайбер элементлары кулланыла.

Балалар бакчаларын оештыру, төрләрен билгеләүдә 1919 елның май аенда узган I Бөтенроссия съезды зур роль уйный. Шул елда дөнья күргән «Балалар бакчасы һәм балалар учагы буенча инструкция» бу өлкәдә беренче төп документ булып тора.

Яңа төр тәрбия оешмалары челтәре барлыкка килгәч, педагоглар алдына әлеге оешмаларның төп максатларын билгеләү, төрләрен ачыклау, һәрбер төрнең тормышка ашыру юлларын һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча методик кулланмалар белән тәэмин итү зарурлыгы килеп баса. Әлеге мәсьәләләрне чишү юллары И. Бикчәнтәй, К. Вәлитова, Г. Айдаров, М. Ялымова, М. Мөштәри һ. б. педагогларның хезмәтләрендә тәкъдим ителә.

Беренче чорда мәктәпкәчә тәрбия йортлары берничә төргә бүленә. Аларга ясленләр, балалар бакчалары, балалар учагы һәм җәйге балалар мәйданчыклары, колонияләр, балалар шәһәрчеге, клублар янында оештырылган балалар почмагы, балалар бүлмәсе һ. б. керә.

Ясленләрне бу вакытта «балалар бишеге» дип тә атап йөрткәннәр. Балалар бишекләренә туганнан алып өч яшькә кадәр булган балалар кабул ителгән. Әлеге төр тәрбия йортларының максаты булып аналарга, бигрәк тә ярдәмчеләре булмаганнарга, яшь баланы тәрбиячеләр кулына калдырып торырга мөмкинлек бирү, баланы авырудан һәм зәгыйфьләнүдән саклап калу, кечкенәдән үк рухи һәм тән тәрбиясе нигезләрен салу торган [5, 41 б.].

Балалар бакчасы һәм балалар учагына 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәр булган балалар йөргән. Бала тән һәм рухи яктан нык, дөрес тәрбия алып, мәктәпкә керергә әзерләнеп чыгарга тиеш булган. Бу төр йортларның максаты «балада булган һәртөрле мәгънәви вә хиссияти куәтләрне үстерү. Баланы зиһен, фикер, аң вә әхлакый җәһаттән юлга салу» [4, 9 б.]. Балалар

бакчасында балалар 6 сәгатькә кадәр генә, ә балалар учагында 8–10 сәгать дәвамында булганнар.

Җәйге балалар мәйданчыклары – балаларның җәй көннәрендә бергә җыйналып уйный торган урыннары. Анда төрле яшьтәге балалар кабул ителгән. Балалар, яшьләренә карап, аерым төркемнәргә бүленгәннәр. Авыл җирләрендә хатын-кызларның күпчелеге кыр эшләре белән мәшгуль булганлыктан, җәйге мәйданчыклар авылларда күбрәк үсеш алган. Мәсәлән, 1927 елда Буа кантонындагы барлык мәктәпкәчә тәрбия йортларының 58 %ын татар балалар мәйданчыклары тәшкил иткән [7, с. 11].

Колонияләр – торак пунктлардан читтә урнашкан, дача тибындагы йортлар. Монда балалар, гаиләләреннән аерылып, даими рәвештә торырга, кирәк-яракны кайгыртуда, шундагы хезмәтләрне үтәүдә тәрбиячеләргә булышлык итәргә тиеш булганнар [5, 41 б.]. Аларны хәзерге замандагы балалар лагерьлары белән чагыштырып карарга мөмкин.

Татар халкы өчен бу төр хезмәт күрсәтү яңа эш булганлыктан, мәктәпкәчә тәрбия йортлары турында гади халыкның мәгълүматы булмый. Балалар бакчаларын оештыручыларның бигрәк тә беренче чорда төрле каршылыкларга очравы да шуның белән билгеләнә. Кайбер очракларда аларны хәтта авылларга да кертмиләр [10, 57 б.]. Шунлыктан, иң беренче чиратта, педагогларга балалар бакчасының нәрсә икәнен, аның нинди максатлардан чыгып төзелгәнен, нинди нәтиҗәләргә китерәчәген гади халыкка аңлатып бирү кирәк була. Халыкның бу төр оешмалар турында мәгълүматы бөтенләй булмаганлыгы түбәндәге мисалда ачык күренеп тора. И. Бикчәнтәев балалар бакчасына аңлатма биреп, болай дип яза: «балалар бакчасы дигәч тә анда, әлбәттә, бакча була, агачлар күп була икән, дия аңланмасын. Ул махсус бер өй булып, балаларны һәр җәһаттә тәрбияләр өчен кирәкле җиһазлары хәзер булган буш йорттан-бинадан гыйбарәт» [4, 9 б.].

Тәрбия йортларын ачканда педагоглар ата-аналар ярдәменә мөрәҗәгать итү кирәклеген ассызыклыйлар. Мәсәлән, балаларны ашату-эчертү өчен савыт-сабалар, гади уенчыклар белән тәэмин итүдә, балаларга уйнау өчен мәйдан ясауда һ. б. шундый күмәк эшләрдә ата-аналар каршы килмәс дип исәплиләр [3, 8–9 б.].

Октябрь революциясеннән соңгы чорда балалар оешмаларының киң таралган төрләре булып балалар бакчалары һәм мәйданчыклар торган. Бу халыкның әле бу елларда баласын озак вакытка үзеннән аерып ясле яисә колония ише оешмаларга бирергә өйрәнмәве белән бәйле була. Әлеге төр оешмаларда баланы тотуның матди яктан күбрәк чыгымнар таләп итүе дә төп сәбәпләрнең берсе булган.

Балалар бакчалары ачыла башлау белән, аларны белемле тәрбиячеләр белән тәэмин итү зарурлыгы туа. Тәрбиячеләр хәзерләү буенча беренче курслар Югары хатын-кызлар курслары каршында оеша. Анда I баскыч мәктәпләреннән яшь укытучылар җибәрелә. 1918 елны Казанда, 1922 елны Чистайда Халык Мәгарифенең Югары институты каршында 2–3 еллык мәктәпкәчә бүлекләр ачыла. 1919–1920 елларда татар һәм башка рус бул-

маган миллəт вəкиллəреннəн тəрбиячелəр хəзерлəү буенча Казанда алты айлык, Чистай, Спас, Чабаксар, Зөя өязлəрендə өч айлык курслар ачыла. 1921 елны мəктəпкəчə оешмаларда эшлəүче татар хатын-кызлары өчен ике айлык курслар оештырыла. Татар педагогия техникумында (хəзерге Казан педагогия көллияте) тəрбиячелəр хəзерлəү буенча махсус бүлек ачыла. Буада һəм Чистайда махсус мəктəпкəчə тəрбия педагогия техникумнары оештырыла.

Мəктəпкəчə тəрбия йортлары, илдə барган сəяси һəм икътисади шартлар нəтиҗəсендə төрлечə үсеш чорлары кичерəлəр. 1918–1920 еллар актив рəвештə төрле төрдəге мəктəпкəчə тəрбия йортлары оештырыла башлау чоры буларак тарихка кереп кала. Беренче вакытта финанслау дəүлəт карамагында була, əлеге оешмалар тоткарлыксыз рəвештə кирəкле күлəмдə матди яктан тəэмин ителеп киленə. Революциядəн соң дəүлəт тарафыннан хосусыйлаштырылган буш биналар күп булу сəбəпле, бина белəн тəэмин итүдə мохтаҗлык тумый. Шунлыктан бу елларда мəктəпкəчə тəрбия йортларының саны шактый арта. 1921–1925 елларда мəктəпкəчə тəрбия оешмаларының саны кискен кими. Моңа, беренче чиратта, 1921 елгы ачлык йогынты ясый. Икенчедəн, финанслауның урындагы бюджетларга күчерелүе сəбəпле, мəктəпкəчə оешмаларның матди хəллəре начарлана, эрелəндерү процессы башлана. Бу сəбəплəр аркасында иң башлап авыллардагы мəктəпкəчə балалар йортлары ябыла башлый һəм озакламый алар барысы да диярлек ябылып бетə [8, 11 б.].

Октябрь революциясенең беренче елларында мəктəпкəчə яшьтəге балалар өчен татар педагоглары тарафыннан татар халкының гореф-гадəтлəрен, тормыш-көнкүрешен күз алдында тотып язылган методик һəм педагогик кулланмалар төзелə. Əлеге хезмəтлəр уен барышында баланың сөйлəм телен үстерүгə, физик һəм хезмəт тəрбиясе бирүгə, балаларда сəламəт яшəү күнекмəлəре булдыруга юнəлдерелгəннəр. Бу эш белəн беренче чиратта үзлəре үк мəктəпкəчə тəрбия йортлары оештырып йөргəн галимнəр шөгыльлəнə. Алардан К. Вəлитова, С. Миңлекəй, М. Ялымова, М. Мөштəри һ. б. ларны санап китəргə була. Алар үзлəренең гамəли һəм тəгълимати хезмəтлəре белəн мəктəпкəчə тəрбия эшенең урнашуына һəм аның таралуына зур йогынты ясыйлар.

## ƏДƏБИЯТ

1. [16 нчы майда балалар бакчасын ачу тантанасы...] // Тормыш. 1915. 21 май.

2. [Бу ел балалар бакчасы…] // Тормыш. 1915. 17 июнь.

3. Балалар мəйданчыгы нəрсə һəм аны ничек төзергə? М.: Нəшрият, 1926. 24 б.

4. Бикчəнтəев И. Мəктəпкə кадəр уку эшлəре / Мəгариф эшлəре. Оренбург: Типо-литография кооперативного союза «Народное Дело», 1918. Б. 9–15.

5. Вəлитова К. Мəктəпкə кадəр тəрбия // Мəгариф. 1921. № 1/2. Б. 36–43.

6. Габдрафикова Л.Р., Измайлов Б.И., Салихов Р.Р. Фирма Алафузова (вторая половина XIX – начало XX века): промышленная история России. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. 276 с.

7. Корнеева М. Очерки по истории общественного дошкольного воспитания в ТАССР (1917–1941 гг.): автореф. дис. ... канд. пед. наук. Казань: 1960. 20 с.

8. Мөхетдинов Н. Татарстан җөмһүриятендә гомуми-мәҗбүри уку кертү мәсьәләләре. Мәктәпкәчә тәрбия // Мәгариф. 1927. № 1. Б. 11–15.

9. Татарская энциклопедия: в 5 т. Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2005. Т.2. 656 с.

10. Хәмидуллин Ф. Беренче балалар бакчасы // Мәгариф. 1967. № 11. Б. 57–58.

11. Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И. История педагогики Татарстана. Казань: КГПУ, 1998. 307 с.

**Автор турында белешмә:** Зиннәтуллина Алсу Әнвәр кызы – фәнни хезмәткәр, Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин урамы, 7, Казан, Российская Федерация); jamash.00@mail.ru

## ПРЕДПОСЫЛКИ ВОЗНИКНОВЕНИЯ ТАТАРСКИХ ДЕТСКИХ УЧРЕЖДЕНИЙ В ГОДЫ ОКТЯБРЬСКОЙ РЕВОЛЮЦИИ И ИХ ПЕРВЫЕ ШАГИ (ПЕРВАЯ ЧЕТВЕРТЬ XX ВЕКА)

***А.А. Зиннатуллина***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*jamash.00@mail.ru*

В статье дается краткий обзор существовавших до Октябрьской революции татарских дошкольных детских учреждений. Раскрываются цели, задачи, типы детских учреждений, возникших в первые годы после революции. Упоминаются татарские педагоги, которые содействовали становлению и развитию татарских детских организаций. Учитывая тот факт, что детские дошкольные учреждения для татарских детей были созданы впервые, показываются способы их учреждения, идеологическая база, на которую опирались авторы при их открытии.

**Ключевые слова:** детские сады, детские дошкольные учреждения, ясли, дошкольное образование, трудовое воспитание, гигиена

**Сведения об авторе:** Зиннатуллина Алсу Анваровна – научный сотрудник, Центр истории и теории национального образования, Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ (420111, ул. Батурина, 7, Казань, Российская Федерация); jamash.00@mail.ru

# PREREQUISITES OF EMERGENCE OF THE TATAR CHILD CARE FACILITIES AND THEIR FIRST STEPS (THE FIRST QUARTER OF THE XXTH CENTURY)

***A.A. Zinnatullina***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*jamash.00@mail.ru*

In article presents a brief overview of the preschool childcare facilities which existed before the October revolution. The main goals and tasks, types of the first childcare facilities that appeared in the first years after the revolution are specified. The Tatar teachers who promoted the formation and development of Tatar children's organizations are mentioned. Considering the fact that preschool institutions for the Tatar children were created for the first time, the article reveals the ways of establishing such institutions and the ideological principles applied by the school authors.

**Keywords:** kindergartens, nursery, nursery schools, children's preschool institutions, preschool education, labor education, hygiene

## REFERENCES

1. 16 nchy majda balalar bakchasyn achu tantanasy [The Ceremonial Opening of a Kindergarten on May 16]. *Tormysh – Life.* 1915. May 21 (In Tatar)

2. Bu el balalar bakchasy [Kindergarten This Year]. *Tormysh – Life.* 1915. June 17 (In Tatar)

3. *Balalar mäjdanchygy närsä häm any nichek tözergä?* [What is a Playground and How to Build It?]. Moscow, Näshriyat Publ., 1926. 24 p. (In Tatar)

4. Bikchäntäev I. Mäktäpkä kadär uku ehshläre [Questions of Preschool Training]. Mägarif ehshlre [Matters of Education]. Orenburg, Typo-lithography of the cooperative union "Narodnoe delo". 1918, pp. 9–15. (In Tatar)

5. Välitova K. Mäktäpkä kadär tärbiya [Preschool Education]. *Mägarif – Education*, 1921, no. 1/2, pp. 36–43. (In Tatar)

6. Gabdrafikova L.R., Izmajlov B.I., Salihov R.R. *Firma Alafuzova (vtoraya polovina XIX nachalo XX veka) promyshlennaya istoriya Rossii* [Alafuzov's Firm (the Second Half of the 19th – Early 20th Century): Industrial History of Russia]. Kazan, Sh. Marjani Institute of History of the TAS. 2015. 276 p. (In Russia)

7. Korneeva M. *Ocherki po istorii obshchestvennogo doshkolnogo vospitaniya v TASSR (1917–1941 gg.) Avtoref. dis... kand. ped. nauk.* [Essays on History of Public Preschool Education in TASSR (1917–1941). Abstract of Candidate Pedagogical Sciences Diss.]. Kazan, 1960. 20 p. (In Russian)

8. Möhetdinov N. Tatarstan cömhüriyatendä gomumi mäcbüri uku kertü mäsäläläre. Mäktäpkächä tärbiya [Issues of Introducing General Compulsory Education in the Republic of Tatarstan. Preschool education]. *Mägarif – Education*, 1927, no.1, pp. 11–15. (In Tatar).

9. *Tatarskaya ehnciklopediya*. [Tatar Encyclopedia]. Vol.2. Kazan, Institute of Tatar Encyclopedia Tatarstan Academy of Science. 2005. 656 p. (In Russian)

10. Hämidullin F. Berenche balalar bakchasy [First kindergarten]. *Mägarif – Education*, 1967, no 11, pp. 57–58. (In Tatar)

11. Sharafutdinov Z.T., Khanbikov Ya.I. *Istoriya pedagogiki Tatarstana* [The History of Tatarstan Pedagogy]. Kazan, KGPU, 1998. 307 p. (In Russian)

**About the author:** Alsou A. Zinnatullina is a Research Fellow, the Center of History and Theory of National Education, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); jamash.00@mail.ru